БУШ АБЗАРЛАР
Тукай районының мең йортлы Биклән авылында ни сәбәпле ун гына сыер асрыйлар?
> 2

ТАТАР УЛЫ
Җиде сугышта катнашкан армия генералы Мәхмүт Гәрәевнең тууына – 100 ел
> 3

ФУТБОЛЛЫ ЯЛЛАР
Татарстан башкаласында «Зенит» белән ЦСКА очрашты
> 4

АРУЛАРМЫ СЕЗ?
Мамадыш районының Җөри авылында таң атканчы Питрау гөрләде
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 101 (29068) | Сишәмбе | 18 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ҖӘЙ АЯККА БАСТЫРА

Машина сатучылар уч төпләрен угалый: җәй, гадәттә, зур сатып-алулар чоры булып саналмаса да, быел автомобиль сату күрсәткече кимеми. Киресенчә, арта. Сәбәпләре дә билгеле: 1 августтан илгә читтән машиналар кертүгә бәйле үзгәреш бәяләр артуга китерергә мөмкин, дип кисәткән белгечләр. Халык та шуңа ашыга, имеш. Автомобиль базарыннан нәрсә көтәсе?

vk.com

Казанда укучы студент Нияз Минаков бу җәйдә машиналы булган.

– Атна ахыры җиткән саен Арчага кайтырга юлчылар эзли-эзли туйдым. Әти-әнием белән киңәштек тә өр-яңа «Lada Vesta» сатып алдык. Машина бәяләре гел кыйммәтләнеп тора бит, эшне сузудан мәгънә юк. Миңа үзебездә җитештерелгән автомобильләр күбрәк ошый. Ватылса, ремонтлау да җиңелрәк. Механика коробкалы, кондиционер, тәрәзәләрне төшерү төймәсе кебек гади кирәк-яраклары булган машина якынча 1,6 миллион сумга төште. Кредит рәсмиләштергәч, «КАСКО» – бүләккә, – ди егет.

«Автостат» белгечләре әйтүенчә, бу җәйдә машина сатып алучылар саны арткан. Бигрәк тә яңа «тимер ат»ларга ешрак күз төшерә башлаганнар. Рәсми мәгълүматларга караганда, июнь аенда әле буяу исе дә кипмәгән 82,4 мең автомобиль сатылган. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу – 2,5 тапкыр күбрәк. Кайсы модельләргә карата кызыксыну зуррак икәнен дә әйткәннәр. Үзебезнең «тимер ат»ларга килгәндә, «Lada Vesta» машинасын җитештерүне әле кабат җайга салырга да өлгермәделәр, ул иң күп сатылучы автомобильләр арасына эләккән дә инде. Яңа сатылган машиналарның 30 проценты «Lada» модельләренә туры килә, ди белгечләр. Чит ил машиналары арасында Кытай җитештерүчеләре алдынгылыкны бирми. Бу – беренче чиратта, аларның чагыштырмача очсыз булуына бәйле, әлбәттә. Ялтырап торган яңа «иномарка»да йөрергә теләүчеләр барыннан да бигрәк «Chery» һәм «Haval»га өстенлек бирә икән.

Кулдан алган «тимер ат»та йөрүчеләр саны да арткан.

– Яңа машина бәяләре «тешли» бит. Шуңа күрә рульдә йөрергә теләүчеләр икенчел базарга килә, – ди алыпсатар Марат Гатауллин. – Салондагы параллель импорт буенча кайтарылган «тимер ат»ка утырганчы, кулда булган машиналар сатылучы базардан искерәк, әмма рәсми дилердан сатып алган «иномарка» эзлиләр. Дөрес, андый автомобильләр күп түгел. Яхшысын сатарга ашыкмыйлар. Ун «яшь» һәм аннан да өлкәнрәк автомобильләр күп сатабыз. Анысын да алучы бар. Статистика мәгълүматларына караганда, бу елның беренче яртысында яңа машиналарның уртача бәясе 2,6 миллион сум торса, кулдагысы – 1,4 миллион сум тирәсе. Бәяләр ике тапкыр диярлек аерыла бит.

Якын арада машиналар тагын да кыйммәтләнергә мөмкин. Һәрхәлдә, белгечләр шулай ди. Быелның 1 августыннан илгә читтән сату өчен кертелүче җиңел, коммерцияле автомобильләр, йөк машиналары һәм автобусларга утильләштерү җыемын индексацияләячәкләр. Бу – яңа «тимер ат»ларга да, искеләренә дә бер үк дәрәҗәдә кагылачак, дип аңлатканнар илнең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында.

Гади сүз белән әйткәндә, утильләштерү җыемы да салымның бер төре инде. Тик бер тапкыр гына түләнә. Утильләштерү җыемы – исеменнән үк аңлашылганча, илдә кулланышта булган транспорт чарасын, ул тузып беткәннән соң, аны яңадан эшкәртүгә тотыла торган акча. Ул экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү, шул исәптән кеше сәламәтлеген һәм әйләнә-тирә мохитне кайгырту максатыннан автомобильләрнең техник торышын исәпкә алып түләнә. 1 августтан әлеге төр җыем күләме җиңел машиналарга 3,7 тапкырга кадәр индексацияләнәчәк дип көтелә. Двигательнең күләменә карап ул 800 мең сумга кадәр җитәргә мөмкин, ди. Шунысын да искәртик: яңалык Россиядә җитештерелгән автомобильләр һәм үзләре өчен читтән двигателенең күләме 3 литрдан артмаган «тимер ат» алып кайтучыларга кагылмаячак. Соңгылары өчен, мәсәлән, элеккеге ташлама гамәлдә кала.

– Аңлашыла ки, шул рәвешле ил автомобиль сәнәгатенә ярдәм итәргә телиләр, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Бәяләр болай да тотрыксыз: доллар курсы үсә, рубль исә, киресенчә, түбән тәгәри. АКШ валютасы чама белән 10 процентка кыйммәтләнгән икән, димәк, бәяләр дә ким дигәндә шулкадәр артачак. Якын арада машина сатып алырга җыенучыларны әнә шул да ашыгырга мәҗбүр иткән, күрәсең. Бүген бар булган автомобильләр сатылса, киләчәктә алып кайтасы машиналар кыйммәтрәк булачак, билгеле. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй: утильләштерү җыемын да арттыралар. Бу – параллель импорт буенча кайтучы һәм безнең халык үз итеп өлгергән Кытай машиналары тагын да кыйммәтләнәчәк дигән сүз.

Белгеч сүзе

Рамил ХӘЙРУЛЛИН, Россия автомобильчеләре федерациясенең Татарстандагы җитәкчесе:

– Машина болай да бик кыйммәт бит инде. Халык куркуга бирелеп, күпләп автомобиль сатып ала башласа, бәяләр тагын да үсәчәк, билгеле. Бүген рульдә йөрүчеләр Кытай автомобильләренә күчеп утырды. Яңалык та, иң беренче чиратта, аларга кагылачак. «Lada» автомобильләренең базарда үз урыны бар инде. Халыкны үзебездә җитештерелгән автомобильләргә күчеп утырырга мәҗбүр итәргә тырышуларын хупламыйм. Чит ил машинасында йөргән кеше, дөнья ничек кенә үзгәрсә дә, иномаркадан баш тартмаячак. Халыкка ярдәм итәргә телиләр икән, тыю-чикләүләр түгел, ә кызыктыру чаралары кирәк. Ташламалы автокредит, субсидияләр, гаиләнең беренче машинасы ише программаларны кабат гамәлгә кертсеннәр. Элек машина зиннәтлелек билгесе булып санала иде, аннары хәрәкәт итү чарасына әйләнде. Бүген исә ул тагын кул җитмәс нәрсәгә әверелеп бара. Аны сатып алу гына да аз, «тимер ат»ны карап тоту да шактый чыгымлы. Запас частьлар дисеңме, иминиятләштерү килешүе, бензин бәясе, машина сатып алу – ярты бәла, машинада йөрү кесәгә суга.

Төзек булсын!

«Халык контроле»нә иң күп керүче мөрәҗәгатьләр территорияләрне төзекләндерүгә бәйле. Гыйнвардан июнь аена кадәр бу мәсьәлә буенча 12 меңнән артыграк заявка алынган. Шуның 10,5 меңе уңай хәл ителгән. Мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче урында – «Юлларны карап тоту һәм төзекләндерү». Әлеге темага 6,3 мең чамасы мөрәҗәгать кереп, 4,1 меңе буенча тиешле карар кабул ителгән. Йортларны карап тоту мәсьәләсе буенча 1604 хәбәр алынып, 1488е хәл ителгән.

Казанда яшәүчеләр системадан иң актив файдаланучылар булып кала (ярты ел эчендә барлыгы 24,1 мең хәбәр калдырганнар). Чаллы халкы (6 мең хәбәр) – икенче урында. Әлмәт районы (2 мең хәбәр) – өченче.

Быел беренче яртыеллыкта «Халык контроле»ндә барлыгы 55 мең мөрәҗәгать пәйда булган. 42 меңе буенча уңай карар чыгарылган.

Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, системаның баш модераторы Сәрия Сабурская әйтүенчә, тагын 9471 мәсьәләне хәл итү буенча эш алып барыла.

Миллионер студентлар

Республикада тагын 242 студент үзләренең эшен үстерүгә берәр миллион сум акча алачак. Дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин әйтүенчә, «Университетның технологик эшмәкәрлек платформасы» федераль проектының өченче бәйгесе буенча Россия күләмендә 1,2 мең студентка грант бирелә. «Республикабыз студентлары – иң яхшы проектлар саны буенча лидер төбәкләр өчлегендә», – дип язган ул үзенең телеграм-каналында.

Министр сүзләренә караганда, проектларның күпчелеге (481 грант) цифрлы технологияләргә бәйле. Тагын 175 студент яңа приборлар һәм производствода «акыллы» технологияләр өлкәсендә үзләренең эшен үстерәчәк.

Узган елда Татарстанның 129 студенты ИТ-проектлар ярдәмендә миллионерга әйләнгән. Аларның барысы да технологик эшмәкәрлек кысасында берәр миллион сум күләмендә грант откан.

Фаш иткәннәр

Россия Үзәк банкы быел гыйнвардан июньгә кадәрге чорда законсыз эшләүче 2449 компаниянең эзенә төшкән. Банк хәбәренә караганда, узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда бу – 7 процентка күбрәк.

Беренче яртыеллыкта 1139 финанс пирамидасы (алдагы елдагыга караганда 19 процентка күбрәк) ачыкланган. Моннан тыш Үзәк банк 850гә якын законсыз кредит оешмасын һәм кыйммәтле кәгазьләр базарында законсыз эшләүче 400 оешманы фаш иткән.

Үзәк банк законсыз эшчәнлекне тыю һәм мошенниклар сайтларын ябу максатыннан, мондый очраклар турында хокук саклау органнарына һәм Монополиягә каршы федераль хезмәткә кичекмәстән хәбәр итә. Беренче яртыеллыкта мондый мәгълүматлар буенча 70кә якын җинаять эше кузгатылган һәм 5 меңгә якын сайт ябылган.

Яшәргә өйрәнәбез

Иске яңа акча

САНЛЫ СУМНЫ НИЧЕК ҺӘМ НӘРСӘГӘ КУЛЛАНЫП БУЛА?

Җисеме яңа, исеме шул. Санлы сум (цифровой рубль) белән эш итү кагыйдәләре Россия Гражданлык кодексында урын алачак. Россия Дәүләт Думасында цифрлы сумны кулланышка кертүгә бәйле закон һәм төзәтмәләр кабул ителде.

Нәрсә ул?

Цифрлы сум – илдәге өченче төр валюта. Цифрлы сум гадәти бер сумга тиң. Цифрлы сум турында кичә-бүген генә сөйләшмиләр инде. Бу елның язынннан башлап аны сынап карау турында фикерләр яңгыраган иде. Кулланышка кертергә дә әзерләнделәр. Ләкин канун ягын кайгыртып бетерергә кирәк иде.

Узган елны иске-яңа акчаны илнең 15 банкы сынап карады. Финанс белгечләре техник ягын тикшерде, акча күчерү, электрон янчыкны тотыру мәсьәләләрен карады. Бу елның июлендә валютаны физик затлар сынап караячак.

Үзәк банк аңлатканча, яңа төр валютаны Дәүләт хезмәтләре порталына теркәлгән, электрон имзасы булган кешеләр куллана алачак. Электрон платформа тәүлек әйләнәсе эшләячәк. Исәп-хисап счетын теләсә кайсы вакытта ябарга да мөмкин.

Сүз уңаеннан, Россия интернет технологияләр үзәге оештырган сораштыру нәтиҗәләренә караганда, илдә яшәүчеләр өченче валюта турында әллә ни белми. Күпләр аңа әлегә ышанмый. Кайсылары исә цифрлы сумның өстенлекләре бар дип саный. Шуларның берсе – бу валюта белән ришвәт бирү авырлаша, ә банкның банкрот калуы шикле, чөнки цифрлы сумны Үзәк банк чыгара.

Нәрсә өчен кирәк?

Кәгазь яисә картадагы акча кебек үк куллану өчен. Хезмәтләр, товарлар өчен түләргә, исәп-хисап эше башкарырга мөмкин.

Законда әлеге валютаны ничек куллану турында тагын берничә яңалык бар. Әйтик, аны башка илләрнең цифрлы сумнарына алмаштыру мөмкинлеге каралачак. Мисал өчен, Кытайның цифрлы юаненә.

Цифрлы сумны саклау өчен бер кеше бер генә «янчык» ача ала. Цифрлы сум белән кредит алу мөмкин түгел. Мондый акча белән түләгән очракта сатып алынган товарлардан кешбәк та каралмаган.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Роза МӨХӘММӘТОВА, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИД һәм йогышлы авыруларны профилактикалау, аларга каршы көрәш буенча республика үзәге психотерапевты:

ВИЧ диагнозына ышану һәм аны кабул итү бик авыр. Беренче реакция – шок, аптырау һәм инкарь итү. Кешегә аның каны тикшерелгән булуын һәм анализның 2 тапкыр уңай нәтиҗә күрсәтүен аңлатырга туры килә. Шуннан соң аңардан авыруны кайдан йоктыра алган булуын сораштырабыз, һәм ул шул вакытта гына чыннан да йоктыру ихималы булганын таный.

(«Татар-информ»)

РОССИЯДӘ – ТУУЧЫЛАР ҺӘМ ҮЛҮЧЕЛӘР

Туучылар >> 407,2 мең кеше

Үлүчеләр >> 595,7 мең кеше

**Росстатның ел башына булган мәгълүматлары буенча*

Унҗиденчесе

Татарстанда, «Бердәм Россия» Бөтенроссия акциясе кысасында, инде 17 нче тапкыр «Мәктәпкә җыенырга булыш!» республика акциясе узачак. Чара, партиянең төбәк бүлеге һәм хәйрия эшчәнлеге советы башлангычында, 2007 елдан бирле үткәрелеп килә.

Республикадан сайланган Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова әйтүенчә, «бердәмроссияле»ләр, узган елдагы кебек үк, Лисичанск шәһәренә уку кирәк-яраклары юллаячак. Бу шәһәрдәге ике меңгә якын укучыга республикадан ярдәм җибәреләчәк. Шулай ук Татарстан карамагындагы Рубежное шәһәренә язу-сызу әйберләре тутырылган рюкзаклар китәчәк.

Акция кысасында мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләре (5,5 меңнән артыграк укучы), шулай ук мәҗбүри күченүчеләрнең балалары да игътибарсыз калмаячак. Моннан тыш, гадәттәгечә, аз керемле, күп балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтеләчәк.

tatarstan.ru



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ГОЛЛИВУДТА БУНТ

Глобаль кризис дөньяның әле бер, әле икенче почмагында аваз сала. Икътисадый вазгыять алга киткән илләрдә дә, үсеп баручы илләрдә дә көннән-көн начарая. Хәтта углеводород сәүдәсеннән гигант табышлар алучы чимал державаларында да финанс хәле начараюга таба юл ала. Согуд Гарәбстаны суверен фонды 2022 елда 11 миллиард доллар акча югалткан. Гарәпләр өчен бу коточарлык хәл түгел, әмма кесә саегаю күңел күтәренкелеге тудырмый. Кытайның Россиядән башка илләр белән товар алмашуы кискен рәвештә кими. Иң күп чимал сатып алучы держаның кризисы бар дөньядагы хәлгә тәэсир итә. Кытайның үз эчендә дә эшләр мактанырлык түгел. Яшерен әҗәтләр кризисы дигән нәрсә баш калкыта.

Кесә хәле моңарчы без балда-майда йөзә дип уйлаган катлауларны да көрәш сукмагына чыгарга мәҗбүр итә. Миллиардлаган доллар акча әйләнүче киноиндустрия үзәге булган Голливудны соңгы көннәрдә фетнә чолгап алды. Йөз меңләгән актер һәм сценарийчы үзләренең эш шартларын яхшыртуны таләп итеп эш ташладылар. Бу – Голливуд тарихында икенче масштаблы кризис. Беренчесе моннан алтмыш еллар элек булган. АКШ киноиндустриясе хәзер паралич хәлендә, югалту күп миллиардлаган доллар белән исәпләнә. Актерлар һәм язучылар стриминг платформалары һәм ясалма интеллект үсеш алган эпохада үзләренә түләү шартлары гадел түгел дип исәплиләр. Тын океан вакыты белән 12 июльдән 13 июльгә каршы төн уртасы җитүгә, АКШның Актерлар альянсы һәм Кино-телевидение продюсерлары альянсы арасында төзелгән контрактның срогы чыккан. Америка язучылар гильдиясе белән продюсерлар арасында төзелгән шундый ук контракт срогы 2 майда чыккан булган. Продюсерлар альянсы яңа контрактлар төзергә ашыкмаган, элекке килешүне дә озынайтмаган. Шул сәбәпле башта меңләгән сценарий авторы забастовкага чыккан, 13 июльдә аларга 160 мең кешене берләштергән Актерлар альянсы кушылган. Иҗат әһелләре белән продюсерлар бәхәсе берничә ай барган икән инде. Актерлар һәм язучыларның төп таләбе – хезмәткә гадел түләү. Хезмәт шартларын яхшыртуны да сорыйлар. Продюсерларның керемнәре арта, инфляция дә көчәя, ә сценарийчыларның һәм башкаручыларның гонорарлары гел бер төрле тора. Вазгыятьнең үз нечкәлекләре күп. Без аларның барысына да тукталып тора алмыйбыз. Актерлар, мәсәлән, кино төшергәндә, ясалма интеллект аларны алыштырмасын дигән таләп тә куялар. Эш шунда: актерларның тышкы кыяфәтен сканлаштыралар да кинода аларның цифрлаштырылган сурәтләре оригиналның рөхсәтеннән башка уйный башлый икән. Хәзерге технологияләр моңа мөмкинлек бирә. Аңлашыла инде: актерга түләнми.

Күп гонорарлы дөньякүләм йолдызлар да, башка актерларга теләктәшлек белдереп, эш ташлады. Киностудияләр зур акча югалта. Хәзергә вазгыять шундый.

Россиядә

ИТ КЫЙММӘТКӘ ТӨШӘ, ИНФЛЯЦИЯ ДӘ ЧИКТӘН УЗА

Россиядә яңа атна зур турбулентлыкта башланып китте. Дүшәмбе таңында, иртәнге сәгать өч тулып узгач, Кырым күперенә ике һөҗүм булды дигән хәбәрләр килеп ирешә. Рәсми хәбәрләр белән телеграм-каналларда куркан шау-шу аерыла, әмма шик юк: хәл гадәттән тыш. Бу юллар язылганда, әле вазгыятькә объектив караш ташлау мөкин түгел, шуңа андый максатны куймыйбыз да.

Бер нәрсәгә шик юк: ашлык килешүе тирәсендә токмачлар куерачак. Эш шунда: 17 июль көнне «ашлык килешүе»нең срогы чыкты. Төрек ягы, Владимир Путин килешүне озайтырга килеште, дип белдерде. Кремльнең рәсми вәкиле Дмитрий Песков исә килешүнең туктатылганын әйтте. Һәм бу карарның күпердәге шартлауга бәйлелеге юк. Әмма Кремль куйган таләпләр үтәлсә, Мәскәү килешүгә кичекмәстән әйләнеп кайтачак. Россия җитәкчелеге Россия ашламасын һәм ашлыгын сату турында БМО биргән гарантияләрне үтәүне сорый. Ләкин БМО карарларының үтәлү очраклары яңа тарихта очрамый диярлек. Әнкара һәм Киев Россия белән өчьяклы килешүдә андый гарантияләрне бирмәде. Сүз ике төрле документ хакында бара. Россия өчен бик җайсыз хәл бу: килешүне өзсә, Әнкара белән ара бозылырга мөмкин. Бездәге икътисадый хәл өчен төрекләр белән хезмәттәшлек хәлиткеч әһәмияткә ия. Әрдоган аннан башка да проблемалар тудыра ала. Шулай да берникадәр паузадан соң Украина ашлыгы Кара диңгез аша озатыла башлар, Россия аяк чалмас дип уйлыйбыз. Ә БМО документлары гадәттәгечә киңәш формасында гына калыр.

Дус илләр белән мөнәсәбәтләрне кискенләштермәгән килеш тә, финанс һәм базар хәлләре мактанырлык түгел. Инфляция Үзәк банк фаразлаган чикләрне узып китәчәк, моңа хәзер рәсми хакимиятләр дә шикләнми. Июль утырышында Үзәк банк төп ставканы күтәрер дип болай да көтелә иде. Яңа турбулентлык процентның югарырак чикләренә омтылу тудырырга мөмкин. Банк проценты – реаль икътисад өчен чып-чын агу ул. Сәнәгатькә инвестицияләр болай да мактанырлык түгел, тагын да кимү көтелә.

Хөкүмәт тарафыннан кертелгән яңа кагыйдәләр болай да кайбер очракларда җитештерүчеләр өчен проблемалар тудыра. 1 сентябрьдән Россиядә чит ил вакциналарын теркәү кагыйдәләре үзгәрә. Эре агрохолдинглар бу уңайдан чаң суга: ветеринария препаратлары кыйммәтләнәчәк, бу ит җитештерүгә сугачак, диләр. Хәзер Россия чит илдән 26 вакцина алса, сентябрьдән аларның 11е генә калачак икән. Россиядә тиңдәше булмаган вакциналарны тыю итнең үзкыйммәтен арттырачак. Авыл хуҗалыгы тармагы вәкилләре шул хакта белдерә. Россельхознадзор моны рәсми рәвештә кире кага кагуын, әмма гадәттә рәсми булмаган хәбәрләр чынга ашучанрак була бит.

Уылдыкка бәяләр 1,5 тапкыр үсте, диләр. Без, гади кешеләр, көн саен уылдык ашамыйбыз инде, әлбәттә. Карасын бигрәк тә. Әмма бәя үсү барыбер шәп нәрсә түгел.

Росстат, илдә дару җитештерү кискен кими, дип белдерә. Сәбәбе: импорт субстанцияләргә бәя күтәрелә. Россиялеләр исә ел башыннан 4,3 миллиард сумлык антидепрессант сатып алганнар. Бу үткән елгыдан күбрәк. Димәк, вазгыять көтелгәнгә караганда яхшырак дигән психотерапия сеансы көтелгәнчә нәтиҗә бирми.

ТӨРКИЯГӘ СӘФӘР

Рәис көндәлеге

Татарстанның Төркия төбәкләре белән хезмәттәшлеге ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга хезмәт итә. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Төркиянең Конья шәһәренә эш сәфәре барышында әйтте.

Республика Төркия икътисадында мөһим урын алып торган һәм илнең авыл хуҗалыгы үзәге булган Конья провинциясе белән элемтәләрне ныгытырга тели. Бу хакта Рәис Конья провинциясе губернаторы Вадәттин Озкан белән очрашу барышында белдерде.

– Татарстан һәм Төркия хезмәттәшлегенең бай тарихы һәм ныклы нигезе бар. Былтыр ике арада товар әйләнеше ике тапкыр үсеп, 1,2 миллиард долларга җитте. Үсеш быел да дәвам итә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул билгеләп үткәнчә, Татарстан белән Коньяның эшлекле мөнәсәбәтләрне арттыру өчен мөмкинлекләре җитәрлек. Ике төбәктә дә авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать тармаклары зур үсеш алган.

– Безгә элемтәләрне ныгытырга кирәк. Сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне үстерү өчен мөмкинлекләр шактый, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Вадәттин Озкан Татарстан Рәисенә Коньяга эш сәфәре өчен рәхмәт белдерде һәм республиканы ил күләмендә алдынгы төбәкләрнең берсе дип атады. «Килешәм, безнең хемәттәшлекне үстерү өчен мөмкинлекләр бик күп», – диде губернатор.

Уртак эшчәнлек турында Конья шәһәре мэры Угур Ибраһим Алтай белән очрашу барышында да сөйләштеләр. Рәис билгеләп үткәнчә, республика делегациясенең Коньяга эш визиты шәһәр белән дә, гомумән, провинция белән дә элемтәләрне ныгытуга юнәлдерелгән.

– Без агросәнәгать юнәлешендә генә түгел, мәдәният, археология, туризм өлкәсендә дә хезмәттәшлек итәргә телибез. Безне бик күп нәрсә бәйли, тагын да тыгызрак аралашырга, эшлекле элемтәләрне үстерергә кирәк. Моңа Казан белән Истанбул арасында туры авиарейслар да ярдәм итәчәк, – диде Рәис.

Рөстәм Миңнеханов Угур Ибраһим Алтайның Төрек дөньясы муниципалитетлары берлеге җитәкчесе вазыйфасында башкарган эшен дә югары бәяләде. Әлеге халыкара оешмага дөньяның 30дан артык илендәге 1200 муниципаль берләшмә керә. Рәис республика муниципаль берләшмәләренә күрсәткән ярдәм өчен рәхмәт тә белдерде.

Очрашуда Кукмара районы башлыгы Сергей Димитриев та катнашты. Ул җирле авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләр белән ныклы хезмәттәшлек урнаштыру теләген җиткерде. Конья башлыгы әлеге тәкъдимне хуплады һәм шәһәрдә мондый предприятиеләр күп булуын билгеләп үтте.

– Сезнең сәфәр үзара сәүдәне киңәйтергә этәргеч бирәчәк, – дигән ышаныч белдерде Угур Ибраһим Алтай.

Коньяда Рөстәм Миңнеханов музейда да булды. Суфи, фәлсәфәче Мәүләна Җәләлетдин Руминың тормышына һәм иҗат юлына багышланган музей Төркиядә халык иң күп йөри торган урыннарның берсе булып санала. Биредә елына 2 миллион турист кунак була. Музейда борынгы китаплар, музыка кораллары, Мәүләнаның шәхси әйберләре урын алган. Биредә төп ядкарьләре арасында Мөхәммәд пәйгамбәрнең сакалы да бар.

tatarstan.ru

Рухыбызны кайгырту

tatarstan.ru

Болгар

Яңа дәвергә аяк басабыз. 15 июльдә изге Болгар җирендә «Яңарыш: дастанның заманча укылышы» фестивале башланды. 23 июльгә кадәр дәвам итәчәк әлеге чараның ачылыш тантанасында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты.

Без монда ни өчен килүебезне, нинди чара уздыруыбызны әлегә тиешенчә бәяләмәдек. Минтимер Шәймиев үз чыгышын фестивальнең әһәмиятен искәртүдән башлады.

– Бүгенге очрашуны истә калдырыйк. Болгар җирендә яңа күренеш, дәвер вакыйгасы уза, – диде ул. – Билгеле булганча, ЮНЕСКО ике юнәлештә эшли: матди һәм матди булмаган мирасны саклау. Матди мирасыбызны – Болгар, Зөя, Казан Кремлен торгыздык, бар дөньяга таныттык. Бәлки, башкалардан күбрәк эшләр башкарганбыздыр. Ә бүген яңа дәвергә аяк басып, матди булмаган мәдәни мирасны торгызуга керешәбез.

«Яңарыш: дастанның заманча укылышы» фестиваленең Болгар җирендә узуы да юкка түгел. Минтимер Шәймиев сүзләре белән әйткәндә, матди мирасыбыз белән бергә рухи мирасыбызны да яңартабыз.

– Мәдәни мирас төшенчәсе гаҗәеп катлаулы ул. Әйтик, дастаннар – тарих, мирас, безнең байлыгыбыз. Бу байлыкны киләчәк буыннарга җиткерергә кирәк. Бу хакта сөйләшә башлаганбыз икән, димәк, без моны эшлибез. Моны башкарып чыгарга сәләтебез җитә, – диде ул.

Исегезгә төшерәбез: фестивальдә теләгән һәр кеше катнаша ала. Болгарда узучы чарага Казан циркы янынннан 15.00 сәгатьтә кузгалучы автобуста барырга мөмкин. Казанга кайту вакыты – 23.00. Билет бәясе – 1000 сум. Сүз уңаеннан, фестиваль кысасында Казан Кремлендә «Мирас һәм традицияләр» күргәзмәсе дә эшли башлады.

Иске яңа акча

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бу – криптамы?

Цифрлы сум – фиат валюта (хөкүмәт чыгарган акча формасы, ул законлы түләү чарасы дип игълан ителгән), ягъни аның тотрыклылыгын дәүләт Үзәк банк ярдәмендә тәэмин итә. Шуңа да ул криптовалютадан аерыла. Криптовалютаның бердәм эмитенты (кыйммәтле кәгазьләр, акча һәм башка активлар чыгаручы оешма), шулай ук кулланучы хокукларын яклау гарантиясе юк. Аның хакы да үзгәрүчән. Цифрлы сум – Үзәк банк җаваплылыгында, цифрлы технологияләр ярдәмендә гамәлгә ашырыла һәм аның криптовалюталарга бернинди дә катнашы юк.

Фикер

Анатолий АКСАКОВ, Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты рәисе:
– Цифрлы сум банк счетларында саклана торган акчаны да, кәгазь акчага да алмаш түгел. Ул акча әйләнешен яңа форма белән тулыландыра гына. Әгәр дә кеше аны кулланырга теләми икән, беркем дә мәҗбүр итмәячәк. Аерма шунда: без бүген товарлар һәм хезмәтләр өчен түләгәндә, акча бер банк счетыннан икенче банк счетына китә. Хәзер акча Үзәк банкның мәгълүмат системасында күренәчәк һәм регулятор, ягъни банк алар өчен җаваплы булачак. Шулай ук смарт-контакт дигән хезмәт тә тормышка ашырылачак. Ягъни акчаны тоту максатын билгеләргә мөмкин булачак. Әйтик, сез балагызга мәктәптә туклану өчен билгеле бер сумма акча күчерәсез, ди. Бала аны бары тик ашауга гына тота алачак, башка максатларда куллану чикләнәчәк.

Борчыган мәсьәлә

МЕҢ ЙОРТКА – УН СЫЕР

Тукай

Мең йортлы Бикләнавылында нибары өч хуҗалыкта ун сыер асрыйлар. Заманасында икешәр көтү чыккан югыйсә. Авыл халкының терлек санын киметүенең сәбәбе нидә?

«Чаллыга якын булгач, авылда йортлар күп салынадыр. Көтү көтәргә урын калмадымы әллә?» – дип сораштык Бикләнавыл җирлеге башлыгы Мансур Сәхбиевтән.

– Юк, сәбәп анда гына түгел. Кайбер авылларның бер ягына чыгасың, сазлык кебегрәк җир. Анда техника белән йөрергә җайсыз, әмма мал көтәргә бер дигән урын. Чишмәсе челтерәп ага. Икенче ягында – урман, аланлык. Анда да көтү көтәргә мөмкин. Тик көтүлек урыннары иркен түгел. Бу – бер сәбәп. Икенчесе – печән чабарга болынлыклар юк. Терлек азыгын сатып ала башласаң, акчасы кирәк. Бик кулай әйбер түгел. Сыерны кеше бер тапкыр бетерә икән, ул аны инде башка асрамый, – диде Мансур Сәхбиев.

Элек авылда терлек асрамаган кеше булмаган диярлек. Заманасында сыерлар саны 380–420гә җиткән. 2005 елга кадәр 100дән артык сыер саналса, аннан кимүгә таба барган. Бүген исә ун гына калган. Шуның өчесе – авыл җирлеге башлыгыныкы, икесе – тренер Марат Мөхәмәдиевләрнеке, калганнары фермер Азат Мостафиннарныкы. «Сыерны кемнәр асрый?» дигән сораугa җавап шул.

«Сыерлы көнем – сыйлы көнем», – дип яшәүчеләрнең берсе – Мөхәмәдиевләр гаиләсе. Хуҗабикә Нурания Мөхәмәдиева Круглое Поле бистәсенә барып, администратор булып эшләсә дә, терлекләрен бетерү ягында түгел. Ике сыерын да кул белән сава. Маллар карарга мәктәптә физкультура дәресләрен укытучы улы Иңгел дә, быел 7 нче сыйныфны тәмамлаган кызы Ләйсән дә ярдәм итә.

– Әти-әниләр дә асрады, без дә бу шөгыльне дәвам иттерәбез. Сөтне үзебез дә, балалар да ярата. Кибетнекен ашыйсы килми. Үзебезнеке тәмле бит. Көнгә 30 литр сөт савам. Эремчек, корт, катык, каймак ясыйм. Бездә сөт җыючы юк. Күршеләр дә, авылдашлар да сорап килгәли. Шәһәрдә яшәүче балаларына күчтәнәчкә дип тә алалар. Өч литрын 200 сумга бирәбез. Сораучылар бар. Барысына да җитми шул, – ди Нурания ханым.

Аннан да авылдашларының сыерларның баш санын бетерү сәбәпләре турында кызыксындык. Нурания Мөхәмәдиева әйтүенчә, авылда хәзер барысының да шәһәрчә яшисе килә. Шуңа күрә бакчасын да, малын да бетерә, хәтта тавык та асрамыйлар. Сыер тотучы абыйапалар картая бара, ә яшьләрнең бик асрыйсы килми. Элек көтү кайтканда күңелле, ниндидер җанлылык бар иде. Кызганыч, хәзер урамнар бушап калган. Бөтен җирне үлән баскан. Менә шул ягы да борчый аны.

– Абзарны бер дә буш тотасы килми. Сыерлар мөгрәп торсын, дибез. Мәшәкате күп, әлбәттә. Икмәге дә кыйммәт. Без пай җирен эшкәртеп, печәнне шуннан әзерлибез. Быел беренче каты начар булды, икенчесенә өметләнәбез. Бу көннәрдә яуган яңгырлардан соң үләннәр күтәрелеп китте, – диде ул.

Мостафиннар исә моңа кадәр ике сыер тотса, соңгы вакытта бишкә җиткән. Таналары бозаулаган икән.

– Ирем фермер булгач, пай җирләрен эшкәртеп, ашлык чәчә, печән үстерә. Шуңа күрә малларны бетермибез. Моңа кадәр сыерларны кул белән сава идем әле. Улым саву аппараты алып кайтып бирде. Хәзер эш җиңеләйде. Бездә – гаилә подряды. Кыз-кияүләр, ул-киленнәр, кодагыйлар белән бергәләп эшлибез, – ди элек почта мөдире булып эшләгән Лиза апа. – Без беркайчан да сыерсыз тормадык. Канга сеңгән гадәт инде ул. Каенанам мәрхүмә Тәнзилә алдынгы сыер савучы, депутат иде. Кеше хәзер бөтен әйберне дә кибеттән генә алып яшәргә өйрәнде. Без үзебез үстергәнне ашыйбыз. Тир түгәргә иренмәсәң, ашы да бар.

Нигә халык сыердан бизгән? Бу сорауны Лиза апага да бирдек.

– Авылда күпфатирлы йортлар да бар. Шуларның ишегалларындагы сарайларны сүтү дә терлек, тавык-чебешләр кимүгә бер сәбәп булды дип уйлыйм. Анда яшәүчеләрнең бакчалары да калмады. Тирә-якны матурайтабыз, балалар мәйданчыклары төзибез, диләр. Бер яктан – файда, ә икенче яктан… – дип көрсенә Лиза ханым.

Авыл кешеләре арасында, шәһәргә барып эшләгәч, сыер асрарга вакыт юк, диючеләр дә булды. Кемдер берәр ел тотып караган да туктаган. Гариповлар да моңа кадәр Чаллыда яшәгән икән. Сигез ел элек авылга күченеп кайтканнар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Үзебез җитештергәне тәмлерәк», – ди Нурания Мөхәмәдиева.

– Монда безнең кебек шәһәр белән авыл арасында яшәүчеләр күп. Ике ара – 15 чакрым гына бит, – ди Фирия апа. – Без үзебез кәҗә асрыйбыз. Малларны абзарда гына тотып булмый бит. Көтүлек җирләре булмау да сыер асрамаска бер киртәдер дип саныйм. Хәзер авыл заманчага әйләнеп бетте. Кайберәүләр урамга мал чыгарганны да яратмый. Мәсьәләнең шул ягы да бар. Кәҗәләр кеше капка төбендә үскән куак, чәчәкләрен ашамасын дип, саклап кына торабыз.

Сәрия МИФТАХОВА

ЙӨЗ МЕҢЛЕК ГАСКӘР УРЫНЫНА... БЕР ТАТАР

АРМИЯ ГЕНЕРАЛЫ, ХӘРБИ ҺӘМ ТАРИХ ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ МӘХМҮТ ӘХМӘТ УЛЫ ГӘРӘЕВНЕҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Горурлык

Рәсми төстә ул алты сугышта катнаша. Әмма бу сугышларның рәсми булмаган җиденчесе дә бар дип санала. Армиядә хезмәт иткән 50 еллык гомерендә Мәхмүт Гәрәев СССР Генштабы начальнигы урынбасары вазыйфасына күтәрелә. Хәрби фән серләрен Мәскәү янындагы окопларда, Ржев сазлыкларында, Кенигсбергны штурмлаган вакытта үзләштерә. Аннан соң гына академиягә килә.

Беренчесе

Беренче сугышта Мәхмүт Гәрәев өчен иң куркынычы фашистлар бомбага тоткан мизгелләр була. Бу хакта ул 1942 елда хәрби корреспондентка сөйли. Ул вакытта әле генә алгы сызыктан күчерелгән батальон урман читендә окоплар казый торган була. Корреспондент: «Куркыныч минутларда нинди хисләр кичерәсез?» – дип командирның теңкәсенә тия. Гәрәев аңа болай аңлата: «Снаряд шартлаган чокырга төшсәң, бәлки, икенче тапкыр ул шул ук урынга эләкмәс тә, әмма өстән бомбага тоталар һәм шунда син берни эшли алмаганыңны аңлыйсың. Иң куркыныч минутлар нәкъ менә шул мескенлегеңне тойган вакытларда була». Бу корреспондент язучы Константин Симонов була.

18 яшьлек кече лейтенант Гәрәев сугышка беренче тапкыр 1941 елның ноябрендә керә. Немецлар шундый якын була ки, казармалардан фронтка кадәр хәрбиләрнең кайсы машинага да утырып тормый, җәяүләп кенә тәпили. Гәрәев ул вакытта взвод кабул итеп алырга тиеш була. Әмма язмыш башкача хәл итеlә. Бу хакта ул китапларында болай искә ала:

«Батальон сугышкан җиргә килеп җиттем. Каршыма кулы бәйләнгән старшина килә. «Батальон командиры кайда?» – дип сорыйм. «Юк», – ди бу. «Офицерлардан кем бар?» «Беркем дә юк, бөтенесе һәлак булды», – ди. Шул вакытта батальон белән командалык итүне үз өстемә алдым. Югыйсә штат буенча комбат – подполковник, иң киме майор булырга тиеш иде. Ике тәүлектән соң батальон командиры килде. Миңа рота тапшырдылар».

Мәхмүт Гәрәевнең тормышы кыл өстендә калган чаклар да була. 1942 елда Калуга өлкәсендә һөҗүмгә барганда, егетне пуля «эзләп» таба. Тик уйлап торыр вакытмыни? Кулын аннан-моннан гына бәйләп куя да кабат сугышка ыргыла. Яңа командир килгәнче, өч көн үтә. Кулы зәңгәрләнеп ката. Медсанбатка барып керүгә, хирурглар әллә ни уйлап тормыйлар: кулын кисәргә карар кылалар. Шунда өлкән яшьтәге бер санитарка ярдәмгә килә: ничек итсә итә, Мәхмүтне эшелонга төяп Рязаньга җибәрүгә ирешә. Анда кулны саклап калалар. Икенче тапкыр Гәрәевнең Витебск янындагы сугышларда башы яралана. Дәвалана да кабат фронтка китә.

1944 елда Мәхмүт Гәрәев батальоны беренче булып Молодечно шәһәренә керә. Юл уңаенда алар Ворошилов исемендәге җирле партизаннардан торган отрядны коткаралар. Анда берничә мең кеше була. Немецлар тылларын чистарту максатыннан партизаннарны юк итү өчен берничә дивизия керткән булалар. Отряд күл янындагы урманга кача, тик немецлар аларны төрле яклап әйләндереп алалар…

Сан

Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы **26,5** млн кешесен югалта. Шуларның **18** миллионы – тыныч халык, оккупацияләнгән территорияләрдә вәхшиләрчә кыланган дошман корбаннары. Бу саннарның дөньяга чыгуында төп рольне Мәхмүт Гәрәев уйный. Ул хәтта сәясәтчеләргә дә бирешми, фикерен үзгәртми.

Очы да, кырые да күренми…

1945 елның 9 Маен майор Гәрәев Ерак Көнчыгышта, хәрби эшелонда каршылый. Япониянe җиңгәч, аны Кытайга җибәрәләр. Анда ул Азатлык армиясе төзергә ярдәм итә. Аннан – Сүрия, Мисыр…

Алтынчы – Әфганстан сугышына генерал-полковник Мәхмүт Гәрәев 1989 елның февралендә килә. Ул вакытта совет гаскәрләрен чыгарырга бер атна вакыт калган була. Вазыйфасы – безнең хәрбиләрнең Президент Нәҗибуллага ярдәм итү өчен төзелгән оператив төркем җитәкчесе. Шул ук вакытта Көнбатыштагы хәрби аналитиклар йөз мең совет солдаты чыкканнан соң Нәҗибулла хакимияте ике-өч атнадан юкка чыгар дип уйлыйлар. Гәрәев 65 яшендә булса да, боерыкны үтәүдән баш тартмый. СССР оборона министры Дмитрий Язов Әфганстанга командировкага китәргә тәгаенләнгән офицерны мондый сүзләр белән каршылый:

– Куркыныч түгелме?

– Миңа куркырга соң инде. 1941 елда Ташкент хәрби училищесын тәмамлаган 119 кеше арасыннан бары тик егерме алтыбыз гына исән калды. Сугыштан соң язмыш миңа болай да 40 елдан артык гомер бүләк итте, үпкәләсәң, гөнаһ булыр… – дигән җавап ишетә.

Президент Нәҗибулла аңа: «Совет гаскәрләре юк бит инде. Сез ничек килергә җөрьәт иттегез? Ничек каршы тора алырбыз икән?» – дигән сорау бирә. Әлбәттә, бу сүзләрдә киная дә сизелә. Гәрәев югалып калмый: «Рус армиясендә яхшы командир бер татардан ике рәт төзи, дигән гыйбарә бар. Мөселманнар бит без, икәүләп тырышырбыз. Рәтләрне дә икеләтә арттырырбыз», – ди.

Чыннан да, бик авыр шартларда эшләргә туры килә. Әфган армиясе бик көчсезләнгән, оештыру эшләре аксый, ышаныч югалган. Мөҗәһитләр гел һөҗүм итеп тора. Эшне активлаштыру, кәефләрен күтәрү өчен бөтен көчне, бөтен хәйләкәрлекне эшкә җигә генерал.

Бер ел ярымнан Мәхмүт Гәрәевне Әфганстаннан чакырып алалар. Бу вакыйга турында Пакьстан газеталарының берсендә: «Руслар Әфганстаннан йөз мең солдатын чыгарды, әмма бер татарны кертте…» – дип язып чыгалар.

Җиденчесе

Хәрби тарих белән шөгыльләнү – Мәхмүт Гәрәев карьерасының аерылгысыз бер өлеше. Петр Гаврилов һәм Брест крепостен яклаучылар батырлыгы турында да халкыбызга аның ярдәме белән җиткерелә. Эш болай була: сугыштан соң берничә ел үткәч, Гәрәевне шушы крепостьта урнашкан дивизия полкы штабына начальник итеп билгелиләр, соңыннан ул анда дивизия командиры була. Сугышчылар биналарны җимерекләрдән арындырганда, коралга, стеналардагы язуларга тап булалар. Гәрәев бу хакта «Огонек» журналына хәбәр итә һәм аннан язучы Сергей Смирнов килә…

Мәхмүт Гәрәевнең иң соңгы китапларыннан берсе «Сражения на военно-историческом фронте» дип атала. Бу китап сугыш турында. Гәрәевнең соңгы көннәренә кадәр гаделлекне саклап калу өчен катнашкан җиденче сугышы турында. Бу – ялган һәм фальсификациягә каршы, Бөек Җиңүнең әһәмиятен юкка чыгарырга теләүчеләргә каршы сугыш. Бу сугышны Мәхмүт Гәрәев һәм Хәрби фәннәр академиясе (ул аның алыштыргысыз президенты була) дистәләрчә ел буена алып бара. Аның дәлилләренә каршы килә алмыйлар. Чөнки үз күзләре белән күргән, башыннан кичергән вакыйгалар сурәтләнгән, фактлар, цифрлар, аргументлар җыелган. Һәр сан артында сугыш кырында ятып калган солдат гомере икәнлеген ул яхшы аңлый. Шуңа күрә берninди бәхәсләшүләргә, һәлак булучыларның санын нindидер максатлар белән киметүгә яки арттыруга юл калдырмый. Ул Бөек Ватан сугышындагы югалтуларны билгеләү буенча комиссия рәисе була һәм: «Югалтулар турында һичшиксез дөресен әйтергә кирәк. Шулай булмаганда, сугыш нәтиҗәләрен һәм Җиңүнең әһәмиятен тулаем күрсәтергә мөмкин булмаячак. Бөек Ватан сугышы турындагы дөреслекне әле бездән соңгы буыннар, язучылар, галимнәр өйрәнәчәк. Бүген җибәрелгән ялган башка ялгышлыкларны да тудырачак», – ди.

Бөек Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итәргә ярты ел калгач, Мәхмүт Гәрәев бакыйлыкка күчә. Әмма аның үткен кораллары булып китаплары кала. Димәк, ул һәрвакытта сафта дигән сүз.

Белешмә

Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев 1923 елның 23 июлендә Чиләбе шәһәрендә күпбалалы гаиләдә туа. Армия генералы. Бөек Ватан сугышында, Япониягә каршы сугышта һәм тагын дүрт локаль конфликтта катнаша. Хәрби һәм тарих фәннәре докторы. 1993 елдан тормышының соңгы көненә кадәр – Хәрби фәннәр академиясе президенты. 250дән артык фәнни һәм публицистик китаплар авторы. Ленин ордены, дүрт Сугышчан Кызыл Байрак ордены, Александр Невский ордены һәм башка бик күп орденнар, медальләр белән бүләкләнә. 2019 елның 27 декабрендә Мытищидагы Федераль хәрби-мемориал зиратта җирләнә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

АКЧАНЫҢ УРЫНЫ БИЛГЕЛЕ

ҮЗАРА САЛЫМ АКЧАСЫНЫҢ «ТӘМ»ЕН БЕЛГӘН БӨРБАШЛЫЛАР БЫЕЛ ДА АНЫ 900 СУМНАН ҖЫЙГАН

Балтач

Соңгы вакытта социаль челтәрләрдә Балтач районындагы Бөрбаш авылы турында «Күлебездә пар аккош», «Безнең яр буе» дигән берсеннән-берсе матур фотолар күренә башлады. Бигрәк тә кичке утлар белән балкып утыручы яр буе күңелгә хуш килде. Авылларга да бик кирәк шул мондый заманча ял итү урыннары!

Яр буе паркы ясау авыл кешеләренең хыялы булып, инде үткән ел эш башлаганнарын белгәнгә, авыл җирлеге башлыгы Равил Галимуллинга шалтыраттым.

– Бик матур килеп чыкты. Авыл халкы булдырган матурлык бу. Шуңа да ул безгә икеләтә кадерле, – диде Равил. – Хыялда катамараннар алу да бар иде, анысы быелга булмас инде. Әле бит җыелган акчадан моңа кадәр эшләнгән урыннарны тәртипкә китерүгә дә өлеш чыгарасы бар. Ел саен шундый 50 мең квадрат метр мәйданның үлән-чүпләрен чаптыртып чистартабыз…

Барысы да моннан берничә ел элек куе чытырманлык баскан урынны чистартып, чаңгы юлы ясарга ниятләүдән башлана. Ниятләре изге булганга, ул шулкадәр уң була! Идея бирүче активистларга бөтен авыл кушыла, 40–50шәр кеше белән сигез көн өмә ясыйлар, агачларны кисәләр, әрәмәлекне чистарталар. Язын исә, куәтле техника, зур суммада акча табып, ул урынны агач төпләреннән арындыралар, аннан чаңгы шуарлык дәрәҗәгә китерәләр. Бүген санап чыкканда гына бик җайлы, җиңел кебек тоела бу эшләр. Агач төпләрен чистарту гына да 500 мең сумга төшә. Ярый әле авылдан чыккан эшмәкәрләр Нияз Галимуллин, Илдар Галиуллин, Бөрбаш Сәрдегәненнән Габделнур Хөсәенов ярдәм итә. Нияз исә әлеге чаңгы юлын яктыртуны үз өстенә ала, әле аннан тыш та чаңгы юлларын тәртипләп тоту өчен кар чанасы, аның артына тагу өчен ике җайланма алып бирә. Менә шушы нәтиҗәне күргән бөрбашлылар әлеге күпернең икенче ягындагы чүплекне дә чистартып, агачларын кисеп, тәртипкә китерә. Дүрт көн өмә ясыйлар. Биредә яр буе паркы төзергә дип килешәләр.

– Үткән ел үзара салым акчасына ул урынга планировка ясаттык, – дип сөйли Равил. – Бу зур чыгымнар сорый торган, үзебезнең көчтән генә килә торган эшләр түгел. Куәтле техникалар кирәк булды. 4100 тонна балчык кына ташылды. Аннан соң 218 метрда җәяүле сукмагы эшләнде. Быелгы үзара салым акчасына һәм егетләрнең матди ярдәме белән 300 метрга якын җәяүле сукмагы, яктыртулар, тирә-юнен тәртипкә китерү эшләре башкарылды.

Башка авылларда 200әр сум җыйганда ук үзара салымны 500әр сум җыйган бөрбашлылар менә ике ел инде аны 900 сумнан җыйганнар. Елдагыча, беренчеләрдән булып җыеп та бетергәннәр һәм бу – райондагы иң зур суммаларның берсе.

– Соңгы елларда эшләгән эшләр кешеләрнең күз алдында бит. Үзара салым акчасын авыл кешесе кирәкле дип санаган урыннарга кулланганын күргәнгә, авылдашлар безгә ышана дип беләм, – ди Равил. – Авылдан чыккан эшмәкәрләрнең күпме ярдәм күрсәтүләрен дә белеп-күреп торалар, бу да – бик зур плюс. Мин безне аңлаган, ярдәм иткән һәркемгә бик рәхмәтле, аларга хөрмәтем чиксез. Иң сөендергәне: бездә авыл язмышына битараф булмаган, «әйдә, аны эшлик, әйдә, моны эшлик» дип идея бирүче, үз артларыннан авыл кешеләрен ияртә алучы активистлар да күп. Авыл халкы да бик активлашты, нинди генә эшкә чакырсак та, каршы килмиләр.

Бөрбашта Бөр елгасыннан аккан су туплана торган зур буа бар. Яр буе паркы әлеге буага үзгә матурлык өстәсә, аның каршы ягында, юлның икенче ягында аккош күле ясарга да, чишмәсен тәртипләргә дә өлгергәннәр инде. Бу – Илдар Галиуллинның чираттагы ярдәме, диделәр, ул инде күлгә бер пар аккош та алып кайтып җибәргән. Дәвамы булыр кебек…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив җәмәгать эшчәнлеге алып баруы өчен «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе **Гобәйдуллин** Әгъзам Самат улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

«Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе вокалчы артисты (солисты) **Игнатьев** Александр Степановичка, «Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе балет артисты **Насыйров** Руслан Госман улына **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Олыяз авылы мәдәният йорты директоры **Шәфиков** Рифкать Минулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татспиртпром» акционер җәмгыятенең «Мамадыш спирт заводы» филиалы спирт производствосы инженер-технологы (смена башлыгы) (Мамадыш шәһәре) **Лепехина** Наталья Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Мамадыш мәктәп-интернаты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Куклев** Андрей Павловичка **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Державин бүләге

Лаеш

«Игелек, дөреслек һәм намуслык үрнәге». Республикада шагыйрь һәм күренекле дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның 280 еллыгын билгеләп үттеләр. Тантаналы чаралар шагыйрьнең туган ягы – Лаеш районында да узды. Биредә Гавриил Державин исемендәге Республика премиясен тапшырдылар.

Премия Державинның үзе кебек – әдәбиятны һәм хокукны берләштерә. Ул әдәбият өлкәсендәге аеруча әһәмияткә ия әсәрләр иҗат иткән язучылар, шагыйрьләр, тәрҗемәчеләр һәм юриспруденция өлкәсендәге фәнни тикшеренүләр алып барган юристларга бирелә. Күләме – 200 мең сум.

Быел Державин премиясе «Казан журналистикасы тарихы турында очерклар (1758–1918)» китабы өчен журналист, документаль телефильмнар авторы Айрат Бик-Булатовка тапшырылды. Җиңүчене Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева бүләкләде.

– Гавриил Романович Державин – Россия юриспруденциясе, мәдәнияте һәм әдәбияты үсешенә зур йогынты ясаган шәхес. Бәйгегә килгән эшләрнең елдан-ел яңача яңгыравына, җитдирәк булуын күрүемә шатмын. Алар укучылар тарафыннан зур игътибарга лаек. Гавриил Державин Россияне данлау өчен бик күп эшләр башкарган. Бүген исә аның шигырьләре, ул яраткан, сакларга тырышкан һәм бик хөрмәт иткән ил даны турында мәдхияләре һәр тарафта яңгырасын, – дип сөйләде Премьер-министр урынбасары.

«Меңгә якын биттән торучы хезмәт – туган ягыма – кадерле Татарстаныма бүләк». Айрат Бик-Булатов үзенең китабы турында әнә шулай диде.

– Республиканың шушы эшемне күрүен бик теләдем. Гавриил Романович Державин – чыннан да, киңкырлы шәхес. Аның зур әдәбиятка юлы журналистикадан, «Казан дворяны» имзасы белән язылган мәкаләләреннән башланган. Журналистиканың күренекле тарихы, бай мирасыбыз бар. Ләкин аны бик аз кеше белә һәм мин бу турыда халыкка күбрәк җиткерергә телим. Барыгызга да бик зур рәхмәт! – диде ул.

Лаеш районы башлыгы урынбасары Татьяна Борһанова, Лаеш халкы үзенең бөек якташын һәрвакыт горурланып искә ала, дип билгеләп үтте.

– Гавриил Державин – игелек, дөреслек һәм намуслык үрнәге. Ярлы гаиләдә туып та, Россия империясенең беренче кешеләренең берсе була. Намуслы, хезмәт сөючән һәм талантлы булсаң, һәрвакыт бар нәрсәгә ирешеп була дигән сүз бу. Бөек шагыйребез турында истәлекне буыннан-буынга тапшыру бик мөһим. Без һәрвакыт аның үзенчәлекле сыйфатларын яшьләребез өчен үрнәк итеп куябыз. Районда күп объектлар Гавриил Романович Державин исемен йөртә. Аның хезмәтләре һәм тырышлыклары дөнья мәдәнияте хәзинәсенә кергән. Без горурланабыз, хөрмәт итәбез һәм хәтерлибез, – диде Татьяна Борһанова.

Бу көнне Лаешта Гавриил Державин исемендәге яңартылган музей да ачылды. Ул «Мәдәният» илкүләм проекты кысасында гамәлгә ашырылган. Музей директоры Фәридә Мортазина яңартылган бинаның заманча җиһазландырылуын билгеләп үтте.

– Музейны яңа технологияләр кулланып, заманча җиһазландырырга тырыштык. Ул Лаеш районы тарихы белән танышырга теләгән күбрәк кешене җәлеп итсен иде, – диде Фәридә Мортазина.

Ләйсән САФИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«ТАИФ» компанияләре төркеме коллективы, танылган галим һәм укытучы

Феликс Галләм улы ШИҺАБЕТДИНОВ

вафат булу сәбәпле, «ТАИФ» акционер җәмгыяте идарәсе рәисенең милекне корпоратив идарә итү һәм инвестицияләр буенча урынбасары Айрат Феликс улы Шиһабетдиновның авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

media.rfs.ru

Үзебезнең бәйрәм кирәк

Казан узган атнада Россиянең футбол башкаласына әверелде. Россия Суперкубогы өчен көрәшкән «Зенит» белән ЦСКА үз артларыннан меңләгән тамашачыны да ияртеп килде. Шул рәвешле, узган сезонда илнең иң шәп футболчыларын күрү бәхетеннән мәхрүм калган җирле спорт сөючеләргә бәйрәм ясадылар. «Рубин» исә премьер-лигада чыгыш ясарга әзерләнә.

Россия Суперкубогы очрашуын карарга «Ак барс Арена»га 40876 тамашачы җыелды. Трибуналарны тутырырга 4 мең чамасы кеше җитмәде. 2018 елдан, ягъни дөнья чемпионаты узганнан бирле Казанның төп стадионына бу кадәр кеше килгәне юк иде. Дөрес, бу юлы уен кырына Аргентина яки Франция «йолдыз»лары чыкмады. Әмма «Рубин»ның узган сезонда беренче лигада чыгыш ясаганын һәм көндәшләрнең дә тамашачыны артык җәлеп итәрлек командалар булмаганын искә алсак, чемпион «Зенит» һәм Россия Кубогы иясе ЦСКАның килүе үзе бер вакыйга инде. Шулай итеп, «Казан Арена»га өч төрле тамашачы җыелды. Беренчеләре – зур футболны сагынучылар. Икенчеләре – җанатарлар саналмаса да, зур вакыйганы үз күзләре белән барып күреп, Сергей Шнуровның чыгышын, Эльмира Кәлимуллинаның Россия гимнын башкарганын видеога төшереп, шуны якыннары белән уртаклашучылар. Өченчеләре исә – «Зенит» белән ЦСКАның тугры фанатлары, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан килүчеләр. Алары дистә меңнән артып китте. Кунакханәләрдә буш урыннар бетте, очкыч билетлары кыйммәтләнде, хокук сакчыларына эш артты. Шәһәр үзәге һәм стадион тирәсе фанатлар белән тулды. Казанга килеп бәйрәм иттеләр, футбол рухын сеңдерделәр. Сүз уңаеннан, 200гә якыны артык бәйрәм иткән, чаманы югалткан өчен полиция кулына да эләкте. Бәйрәм үпкәсез генә булмый инде.

Россиядә яңа футбол сезонының ачылышын игълан иткән хәлиткеч уен исә ничьяга тәмамланды. Җиңүчесез булмый бит инде, шуңа күрә матч ахырында Суперкубок иясен пенальтилар ярдәмендә ачыкларга туры килде. ЦСКАга өстенлек бирүчеләр күбрәк иде: ни дисәң дә, Мәскәү командасының капкасын Игорь Акинфеев саклый. Әмма ул тупны бер генә тапкыр тота алды. Михаил Кержаков исә осталыгын ике мәртәбә раслады һәм «Зенит» 8 нче тапкыр Суперкубокны яулады. Хәзер Санкт-Петербург клубының Россиядә барлыгы 22 зур җиңүе бар. ЦСКАныкы – 21. Бу гына җитмәгән, дүшәмбе «Зенит» тагын бер мәртәбә ЦСКАның борынына чиертте: күп еллар дәвамында Мәскәү командасында чыгыш ясаган һәм төп уенчылардан берсе саналган Марио Фернандес белән килешү төзегәнен игълан итте. Шәп футболчы, җитмәсә, Россия паспортына да ия.

Очрашудан соң барысы да Казанның әлеге бәйрәмне матур итеп оештырганы өчен рәхмәт әйттеләр. Әмма Казандагы футбол тамашачысына мондый бәйрәм генә аз. Кем әйтмешли, күрше урамдагы туй кебек. Барысы да таныш кебек, тик читтән генә карап торырга ярый, ә эчкә кертмиләр. Чын җанатарларга «Рубин»ның уеннары кирәк. Күп калмады. Премьер-лигага әйләнеп кайткан Казан командасы сезонның тәүге очрашуын 22 июльдә Мәскәүдә җирле «Локомотив»ка каршы уздыра. Ә үз кырындагы беренче очрашуда 30 июльдә «Оренбург»ны кабул итә.

Безнекеләр бу очрашуга бик җитди әзерләнә дип аңларга кирәк. Якшәмбе көнне үзбәкләрнең «Турон» командасына каршы узган уенга тамашачыны түгел, журналистларны да чакырмадылар, хәтта трансляциясе дә узмады. Дөрес, Казанда Суперкубок очрашуы булган көнне, әйтерсең, безне дә онытмагыз дигән кебек, «Рубин» үз базасында җанатарлар белән очрашу оештырды. Бергә уен уйнадылар, бераз тамак ялгадылар, хәл белештеләр, яңа сезонга дип әзерләнгән формаларын күрсәттеләр.

Шул арада Казан командасы үз составын да ныгыта. Киткәннәрне саный башласак, озакка китәр. Ни дисәң дә, беренче лигада уйнаганда башкала клубы ике командалык футболчы җыйган иде. Хәзер исә «иң-иң»нәрен генә калдырып, тагын көчәймәкчеләр. Соңгы арада башкала клубы 4 чит ил уенчысы белән килешү төзеде. Иң беренче булып «Рубин»га Мацей Рыбус килде. 33 яшьлек поляк футболчысы инде 2012 елдан бирле Россиядә чыгыш ясый. Башта «Рубин»ның хәзерге баш тренеры Рәшит Рәхимов кулы астында «Терек»та уйнады, Франциягә барып кайткач, «Локомотив» һәм «Спартак»та туп типте. Ярымсакчы премьер-лигада барлыгы 211 очрашуда катнашып, 22 туп кертте һәм 27 нәтиҗәле пас бирде. Черногория җыелма командасы уенчысы Игор Вуячичка – 29 яшь. Сакчы соңгы вакытта Сербиянең «Партизан» командасында уйнады. Косоводан килгән Мирлинд Дакуга – 25 яшь. Моңа кадәр һөҗүмче Словениядә чыгыш ясады. Әле якшәмбе көнне генә «Рубин» ярымсакчы Иву Угочукву белән килешү төзеде. 23 яшьлек футболчы Нигериядә туып-үскән, әмма Әрмәнстан җыелма командасы уенчысы санала. Узган ел Әрмәнстан премьер-лигасының иң яхшы уенчысы булып танылган иде. Яңа сезонда исә Акинфеев һәм Фернандеска каршы уйнарга туры киләчәк.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

МИЛЛӘТНЕҢ ӘХЛАКЫЙ КОДЕКСЫ

«ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ»НЕҢ ЯҢА БАСМАСЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ

Мин кулыма китап алам...

Балалар үзебезнең әкиятләрне тыңлап һәм укып үссен иде! Нәкъ менә шул максаттан, Татарстан китап нәшрияты зур тиражда «Татар халык әкиятләре»нең яңа басмасын тәкъдим итте. Гаҗәеп төгәл һәм сабый күңеленә үтеп керердәй рәсемнәр белән бизәлгән бу җыентык нәрсәсе белән үзенчәлекле?

Лилия Гыймазова

Нәшрият әлеге проектны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе инициативасы нигезендә гамәлгә ашырган. 10 мең данә тираж белән нәшер ителгән җыентыкта сез һәм без яраткан әкиятләр тупланган. Гомуми тиражның җиде меңе татар телендә булса, өч меңе рус теленә тәрҗемә ителгән.

– Биш мең китап мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына таратылачак. Бушлай, билгеле. Балаларыбыз шушы әкиятләрне тыңлап, укып үсәр дип өметләнәбез, – дип сөйләде безгә китап нәшриятының генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин. – Халык әкиятләренең әһәмияте турында әйтеп торасы да юк. Бу басманың төп үзенчәлеге – андагы рәсемнәр. Аларны балалар китапларына иллюстрацияләр ясау буенча беренче номерлы рәссам – Фәридә Хәсьянова иҗат итте.

Әлеге басма инде сатуда бар. Гаҗәеп бизәлешле һәм мәңге актуаль булып калачак бу китапның бәясе якынча 500 сум гына.

– Комиссия ярдәме белән эшләнгәч, бу китапның бәясе хәтта үзкыйммәтеннән дә арзанрак. Моннан тыш, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тарафыннан типография чыгымнары өчен субсидия бүленеп бирелә. Татарстан китап нәшрияты кибетләрендәге басмалар шуңа да чагыштырмача арзан була. Ә инде бүтән, шул исәптән интернет кибетләрдә сатучылар үз бәяләрен куя, – дип аңлатты Илдар Сәгъдәтшин.

Галия Шакирова тарафыннан төзелгән әлеге әкиятләр җыентыгы белән таныш кешеләр дә бардыр. Аны үз вакытында тиз арада алып бетергән булганнар. Нәкъ менә әлеге җыентыкка ихтыяҗ зур булгач, тагын бер басмасын чыгарырга карар кылынган. Илдар Сәгъдәтшин ашыгырга киңәш итте: чагыштырмача зур тираж белән чыкса да, монысын да китап киштәләрендә озак тотмаслар...

«Хатын-кызга бала күңелен аңлау җиңелрәк»

Өч ел гомер! «Татар халык әкиятләре»нең рәссамы Фәридә Хәсьянова иллюстрацияләргә әнә шулкадәр вакыт кирәк булды ди.

– Бу иллюстрацияләрне 17 еллап элек үк иҗат иткән идем. Ни өчен шулай озак вакыт кирәк булды, диярсез. Әкият бит ул – милләтнең әхлакый кодексы. Халык әкиятләренә иллюстрация ясау – гаять зур җаваплылык. Ул – бик озаклап эзләнүне, үз тарихыңны, халкыңның яшәешен, көнкүрешен яхшы белүне таләп итә торган фәнни эш. Әкиятләрне укып, иллюстрацияләрен карап, синең халкың турында башка халык вәкилләре мәгълүмат ала. Ә мин халкыбызны матур итеп күрсәтергә, башкаларны гашыйк иттерергә теләдем. Шуңа да бу эшне чираттагы заказ буларак түгел, ә миссия буларак кабул иттем, – дип сөйләде Фәридә ханым.

Фәнни дәрәҗәдәге төгәллек уңышның бер өлеше булса, осталык – икенчесе. Балалар өчен һәм аларны аңлап рәсемнәр ясау һәркемгә дә бирелми бит.

– Рәсемнәрне ясау осталыгы – турыдан-туры укучының йөрәгенә илтә торган юл. Минемчә, хатын-кызга бала күңелен аңлау җиңелрәктер ул. Әни, дәү әни булгач, сабый күңеленең кайсы кылларын тибрәтәсен, йөрәгенә ничек барып җитәсен яхшырак тоемлыйсың, – дип аңлатты рәссам.

Кызганыч, соңгы елларда дөнья күргән балалар китапларының күбесен озаклап актарасы килеп тормый. Алардагы иллюстрацияләрнең сыйфаты Фәридә ханым Хәсьянованы да борчый.

– Бүген без шундый заманда яшибез: нинди генә өлкәне алсак та, профессионализм җуела. Шул исәптән рәсем сәнгате өлкәсендә. Әйтик, табиблар белән чагыштырып карасаң, оста рәссамнарның аз булуы ул дәрәҗәдә куркыныч түгел кебек тоеладыр. Ләкин бу очракта глобаль яктан карарга кирәк. Дистәләгән еллар узгач, нәрсә булыр? Рухыбыз нишләр? Мин гомерем буе диярлек татарларны сәнгать аша дөнья масштабында күтәрергә, башка халыклар белән тигез итеп күрсәтергә омтылдым, үз халкымның чын патриоты булдым. Һәм, әлбәттә, бу сәнгатьнең шулай артка тәгәрәве мине бик борчый...

Ренат ХАРИС, Татарстанның халык шагыйре:

> Гомернең бер чорында да әкияттән ераклашырга ярамый, чөнки кешенең рухы – әкиятләр дәвамы. Әкиятен белгән халык – үзен үзе аңлаган халык ул. Ә андый халык – әкияте кебек үк – үлемсез!
>
> *(Җыентыкка кереш сүздән)*

ТАГЫ ДА БЕРГӘ ҖӨРСӘК ИДЕ...

Тырлау аланына кич җиткәнче килгән идек, кояш чыкканда кайтып киттек. Мамадыш районының Җөри авылында узган Питрау быел да таң әтәчләре кычкырганчы гөрләде. Керәшен мәдәниятенең дини чараларыннан саналган бу бәйрәм 25 ел эчендә бар халыклар өчен күңел ачу чарасына әйләнде.

«Татар-информ» / Абдул Фархан

Корал урынына – капчык

Милли бәйрәмнәрдә ачылыш тантанасы аерым игътибарга лаек була – моны барыбыз да беләбез кебек. Питрауның да бу өлеше, сәгатьләр буена сузылып, ел саен иң күп тамашачы җыела торган урынга әверелә. Быел исә әлеге бәйрәмнең ачылышын ямьле итәргә артистлар гына түгел, табигать тә булышты. Җир-анага дан җыруы җырланганда күкне каплаган караңгы болытлар арасыннан ялтырап кояш чыкты. Прологның нәкъ менә ул мизгелләре могҗизага тиң иде.

Янә бер кат үткәннәргә алып кайткан ачылыш тантанасында Тәңре, Җир-су, Умай турында риваятьләр дә ишеттек, һәр ыруның Изге тавы булганлыгы турында да белдек. Шул арада кайбер уеннарның тарихын да сөйләделәр. Әйтик, әүвәлге заманнарда сугышчыларны атка утыртканчы, корал урынына капчык тоттырып, бүрәнәгә утыртканнар. Капчык сугышы шуннан килеп чыккан да инде. Сугышчылар, димәктән, прологта батырлык, ир-ат тәрбиясенә аерым урын бирелгән иде.

Тырлауда кемнәр бар?

Патриотик рухтагы ачылыш тантанасы котлаулар белән дәвам итте. Тырлау аланына җыелган кунакларны тәбрикләргә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин килгән иде. Аңа да таң атканчы күңел ачарга тәкъдим иткәннәр.

– Питрауны «чәчәкләр бәйрәме» дип тә атыйлар, ул русларның Каравоны, татарларның Сабан туе, чуашларның Уявы, мариларның Семыгы белән беррәттән чирек гасыр дәвамында Татарстанда яшәүче халыклар арасындагы дуслык, үзара аңлашу мохитен булдыруга ярдәм итә. Бүген Питрау Татарстанның танылган брендларының берсенә әверелде. Тырлау аланына килүчеләр арасында яшьләрнең күп булуы бик сөендерә, – диде парламент Рәисе.

Мөхтәрәм кунаклар арасында Росприроднадзор җитәкчесе Светлана Родионова да бар иде. Мамадыш аның әнисенең туган ягы икән, шуңа да ул бәйрәм котлаганда күз яшьләрен тыя алмады.

– Минем әнием Мамадышта туган һәм бик иртә ятим калган. Әмма, аның сөйләүләре буенча, ул монда үзен бер минут та ятим итеп тоймаган. Әниемнең үзенә ярдәм иткән күршеләренә, якыннарына рәхмәтле булуын ишетеп үстем. Шуңа да мин монда чиста күңелле кешеләр яшәвен бик яхшы беләм. Бирендә «күңел экологиясе» һәр агачның тамырына, һәр кешегә сеңгән, – диде ул.

Питрау – Петр һәм Павел апостоллар хөрмәтенә уздырыла торган дини чарадан чын мәгънәсендә заманча бәйрәмгә әйләнде. Мамадыш районы башлыгы Анатолий Иванов шулай ди.

– Питрау чирек гасыр дәвамында бик күпләрне үзенә гашыйк итте. Ул чын мәгънәсендә барлык халыкларның бердәмлеге, хөрмәт һәм горурлык бәйрәменә әверелде. Быел – Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында ул аеруча зур әһәмияткә ия.

Татарстанның керәшеннәр җәмгыяте башлыгы Иван Егоров фикеренчә, бүгенге шартларда без тагын да ныграк берләшергә тиеш.

– Быел бәйрәмебезнең 25 еллык юбилеен билгеләп үтәбез. Кечкенә генә авыл җыеныннан Питрау республика дәрәҗәсенә күтәрелде. Илебездә таралып яшәгән карендәшләребезне Питрау бер урынга җыя. Алай гына да түгел, кечкенә генә Тырлау аланы төрледән-төрле милләт кешесен үзенә сыендырды, – дип сөйләде ул.

«Монда җылырак...»

Тырлау аланы буйлап «җөреш»не Татарстанның төрле районнары әзерләгән ишегалларына кунакка кереп дәвам иттек. Зәйдән килгән Роза түтидән менә шулай җыелышуның әһәмияте турында сораштык.

– Бу арада көн саен бәйрәмдә әле. Ерак дип тормыйбыз, ел саен диярлек Җөригә дә киләбез. Питрау бит ул – үзенчәлекле бәйрәм. Иң җылысы, дип әйтимме соң... Безнең халык киң күңелле, кунак сөючән булгангадыр инде. Монда килеп, башка карендәшләр белән очрашкач, рәхәт булып китә. Үзебезне дә күрсәтәбез, җырлыйбыз-биибез, – дип сөйләде ул.

Ишегаллары буйлап барганда, иң күп кеше җыелган урынны читләтеп уза алмадык. Такыя үрүчеләр почмагы елның-елында гүзәл затларның иң яраткан урынына әйләнә дә куя шул. Иң матур такыяны «эләктереп», фотога төшеп калырга кирәк чөнки. Аларны үрүчеләр сөйләве буенча, такыя үрү өчен барлык файдалы үзлекләргә ия булган Питрау чәчәкләре кирәк. Алар ким дигәндә 12 төрле булырга тиеш. Аның һәркайсы билгеле бер сыйфатны белдерә. Мәсәлән, мәк чәчәге – сагыш, ромашка – сафлык, ягымлылык билгесе. Элек-электән кызлар күңелләрендә булганын такыяларына күчергән.

Чираттагы тукталышыбыз – «Димче почмагы». Монда килеп, кавышып, гаилә корып, матур тормыш кичерүчеләр бүген дә бар, ди әле. Атаклы димче Аграфена Васильева кавыштырсамы... Елдагыча, исем һәм телефон номерын язып калдыру өчен махсус такталары әзерләнгән. Телефон номерын калдыручы 15ләп егет һәм 10лап туташны санадык.

Һәрхәлдә, Питрауда уздырыла торган «Керәшен чибәре» бәйгесеннән соң ел саен яңа гаилә туа. 2021 елда җиңгән кыз да, узган елны таҗ кигәне дә шул ук елны кияүгә чыкты. Чиратта – Теләче районы кызы Анжелика Павлова. Төп бүләк – «Керәшен чибәре» таҗын быел ул киде. Ә җиңү өчен барлыгы 10 кыз көч сынашкан иде. Чибәрлектә генә түгел, билгеле. Йолаларны, телне, мәдәниятне белү дәрәҗәсен дә тикшерделәр, җырлатып, биетеп тә алдылар үзләрен.

Иртәнге чык тамчылары төшә башлаганда, ниһаять, көрәш тә тәмамланды. Өченче ел рәттән Питрауның төп батыры исемен Зәй егете Радик Сәлахов яулады. Аңа быел машина түгел, 500 мең сумлык акчалата бүләк тапшырдылар. Хәер, Радикның машиналары болай да җитәрлек инде ул. Үсмерләр арасында исә Арча егете Дияр Муратов батыр калды.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 301

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+